Республика Татарстан
Глава Бизякинского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423648, село Бизяки,
ул. Центральная. 46

Татарстан Республикасы
Менделеев
муниципаль районы
Бәзәкә авылжирлеге
башкарма комитеты
423648, Бәзәкә авылы,
Узәк урам, 46

Тел./факс 3-47-34

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.11.2023 № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2023 елның 24 ноябре 10.00 сәг. Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2023 елның 24 ноябре 13.00 сәг. Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының икнче этабын билгеләргә.

3. 2023 елның 24 ноябре 16.00 сәг. Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

4. Җыеннарның барлык этапларын уздыру урынын адреслар буенча:

Беренче этап: Бәзәкә авылы, Яңа урам, 1 йорт, авыл мәдәният йорты
икенче этап: Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 йорт, административ бина
өченче этап: Бәзәкә авылы, Яр буе урамы

5. Бәзәкә авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Яшьләр урамы, 1 йорттан 126 йортка кадәр, Елга арты урамы, 1 йорттан 106 йортка кадәр, Яңа урам, 1 йорттан 36 йортка кадәр
Икенче этап: Үзәк урам, 1 йорттан 102 йортка кадәр

Өченче этап: Яр буе урамы, 1 йорттан 36 йортка кадәр
Дуслык урамы, 1 йорттан 14 йортка кадәр, Бакча урамы 1 йорттан 11 йортка кадәр
Рифкат Таҗиев урамы 4, 7 йортлар, Урман урамы 10 йорт

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авылы җирлегенең Бәзәкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. Бәзәкә авылында насос сатып алу
2. Бәзәкә авылында янгын сүндерү машинасы өчен янгын сүндерү җиһазлары, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу
3. Бәзәкә авылында юлларны кардан чистарту
4. Бәзәкә авылында вак таш сатып алу, ташу, тигезләү
5. Бәзәкә авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр
6. Бәзәкә авылында үлән чабу
7. Бәзәкә авылында урам яктыртуны ремонтлау, яктырткычлар сатып алу
8. Бәзәкә авылында чишмәне ремонтлау, территорияне төзекләндерү
9. Бәзәкә авылында "Үлемсез полк" стендын ясау
10. Бәзәкә авылына керү урынында стелла ясау һәм урнаштыру
11. Бәзәкә авылында үлән чабу өчен триммер сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов